Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.02.2023 ел Менделеевск ш. №64

Менделеевск шәһәре территориясе буенча узучы
даими муниципаль автобус маршрутларында
җайга салынмый торган тарифлар буенча
пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны
гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс оештыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны рәсмиләштерү, даими пассажирлар йөртү маршруты һәм даими маршрут карталары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкларны яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 559 номерлы карары нигезендә Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурсны заказ бирүче һәм оештыручы итеп Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетын билгеләргә.

3. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясе буенча узучы даими муниципаль автобус маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс үткәрүне 2023 елның 27 февраленә кадәр тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр хуҗалыгы буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары С.В.Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелде
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Башкарма комитет җитәкчесенең
шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В.Метальников

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 8 февралендәге 64 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның бер яисә берничә муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыклар алу хокукына ачык конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

- Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - Р.Р. Искәндәров;

Комиссия әгъзалары:

- Менделеевск районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары - С.В. Метальников;
- Менделеевск муниципаль районының инфраструктура һәм инвестиция үсеше идарәсе» МАУның юл хуҗалыгы программаларын формалаштыру бүлеге башлыгы - П.А. Маштаков
- "Административ-хуҗалык идарәсе" МБУ директоры - Л.И. Салихова.